ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 45-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 45-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 190-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Законы

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» 2011 елның 10 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 өлешнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 6 өлештә «, 6» санын төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатыннан эшләнде.

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 393-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының территориаль үсеш зоналары резидентларына инвестицияле салым кредитлары бирү каралган беренче өлешендәге аерым нигезләмәләр үз көчен югалткан дип танылды. Әлеге үзгәрешләр «Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә территориаль үсеш зоналары режимын бетерүгә бәйле.

Закон проекты белән шундый ук үзгәрешләрне «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законына кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турында карарны килештерү һәм кабул итү тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 6 сентябрендәге 642 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.